ТАТАРСТАН Республикасы
Аксубай муниципаль районы
муниципаль беремлеге
Емелькино авылы

Республика ТАТАРСТАН
Аксубаевский
муниципальный район
муниципальное образование
село Емелькино

**Совет Емелькинского сельского поселения**

423056, Республика Татарстан, Аксубаевский муниципальный район, село Емелькино, ул. Центральная д.16
Тел.(8-84344-4-76-22) ОГРН 1021605364980, ОКПО 94318599,ИНН/КПП 1603000796/160301001

КАРАР

№ 2 13 ноября 2025 ел

«Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлеге
Сосновка авылында гражданнарның үзара салым
акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
гражданнар җыенын билгеләү турында"

«Халык хакимиятенең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Аксубай муниципаль районының «Емельки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә

Карар бирәм:

1. 2025 елның 13 декабрендә 14 сәгать 00 минутка авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлегенең Сосновка авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә: ТР, Аксубай районы, Сосновка авылы, Зеленая урамы, 5 йорт.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:
Аксубай муниципаль районы Емелькино авыл җирлегенең Сосновка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, хәрби хезмәткә чакырылган, өлешчә мобилизацияләнгән һәм.контракт буенча хәрби хезмәткәрләрдән ,аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, , 2026 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә,алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

1.Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- торак пункт чикләрендә урамнарны кыш көне карап тоту (ягулык-майлау материаллары сатып алу, эшләр өчен түләү);

2.Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, аның предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән Кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- Торак пункт территориясен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияне чабу - ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү)
- Урамнарны яктырту җайланмасы (торак пункт чикләрендә урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен шартнамә буенча товарлар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;)

3. Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, су агызуны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру

- су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аларны чистарту, транспортировкалау һәм халыкка су бирү (су башнясы территориясен киртәләү, шартнамә буенча материал сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү) белән тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау

| | | |
|---|---|---|
| «РИЗА» | "КАРШЫ" | «ТЫЕЛЫП КАЛДЫМ» |

4.Әлеге карарны Емелькино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга. http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru/

Аксубай муниципаль районы
Емелькино авыл җирлеге башлыгы Н.И.Михайлова